**9нчы билет**

| Биремнәр | җаваплар |
|---|---|
| **1. Саннарны дөрес итеп укыгыз.**<br>1918, 10 000 000, 78, 101, 8,12,40, 387,49. | 1.Бер мең тугыз йөз унсигез, ун миллион, җитмеш сигез, йөз бер, сигез, унике, кырык, өч йөз сиксән җиде, кырык тугыз. |
| **2. Тәрҗемә итегез, 4-5 җөмлә төзегез.**<br>После болезни, кроме яблок, с доктором, для раненых, каждый час, через окно, как родной, о жизни, к палате, несмотря на боль, против ветра. | 2.<br>Авырудан соң, алмалардан башка, табиб белән, яралылар өчен, сәгать саен, тәрәзә аша, туган кебек, тормыш турында, палата янына, авыртуга карамастан, җилгә каршы.<br>Әнием табиб белән бик озак сөйләште. (Мама долго разговаривала с доктором)<br>Мин тәрәзә аша урамга карап утырдым. “Тормыш турында китаплар укырга яратам”, - диде дустым. Авырудан соң урамда озак йөрергә ярамый. |
| **3. Әниегез сезгә эш куша һәм тиз эшләп бетерү шартын (условие) куя. Сез бу хакта иптәшләрегезгә әйтәсез, алар сезгә булышырга теләк белдерә. Нинди сөйләшү булыр:**<br>а) әниегез белән сезнең арада;<br>ә) яшьтәшләрегез белән сезнең арада. | а) – Әнием, дуслар белән урамга чыгарга ярыймы? Дуслар белән футбол уйнарга җыенабыз.<br>- Улым, ике түтәл чүп утасаң, чәчәкләргә су сипсәң, дусларың белән урамга чыгарсың.<br>ә) – Антон, әйдә футбол уйнарга!<br>- Миңа әнием эш кушты. Эшләп бетергәч, чыгармын.<br>- Әйдә, без сиңа булышабыз! Нәрсә эшләргә кирәк?<br>- Ике түтәл чүп утарга, чәчәкләргә су сибәргә.<br>- Антон, син чәчәкләргә су сип, ә без Коля белән чүп утыйбыз. |
| **4. Бу мәкальне ничек аңлыйсыз? Фикерегезне языгыз.**<br>Ата-ананы тыңлаган адәм булган,<br>Тыңламаган әрәм булган (пропал). | 4.Әгәр ата-анаңның сүзен тыңласаң, кушкан эшләрен эшләп барсаң, димәк, син - тәрбияле, әдәпле, тыңлаучан бала. Син киләчәктә уңышларга ирешерсең. Ә ата-ананың сүзен тыңламаган балага киләчәк торышта авыр булачак, чөнки ул бернинди эш эләп үсмәгән, бернәрсәгә дә өйрәнмәгән булып үскән. Андый кеше тормышта югала, чыннан да әрәм була, дип уйлыйм. |
| **5. Как скажешь о том, что:**<br>- надо уступать место старшим, женщине с ребёнком, дедушкам, бабушкам;<br>- грубость, невоспитанность не украшают людей;<br>- застенчивость – не всегда положительная черта характера;<br>- нельзя смеяться над недостатками людей. | 5.<br>- Өлкән кешеләргә, әби-бабайларга,балалы хатын-кызларга урын бирергә кирәк.<br>- Тәрбиясезлек һәм тупаслык кешеләрне бизәми.<br>- Оялчан булу - һәрвакытта да уңай сыйфат түгел.<br>- Кешеләрнең кимчелекләреннән көлергә ярамый. |